**5 класс белем бирү минимумы 2 чирек**

1.Хромасомалар – бер күзәнәктән икенче күзәнәккә нәселдәнлек информациясе тапшыралар

2.Тукыма – чыгышы, төзелеше буенча охшаш һәм бертөрле функция башкара торган күзәнәкләр һәм күзәнәкара матдә җыелмасын атыйлар.

3. Япма тукыма – саклагыч функцияне үти.Алар бер-берсенә тыгыз орынып урнашкан, калынайган тышчалы тере яки үлгән күзәнәкләрдән тора.

4. Механик тукыма – үсемлекләргә ныклык бирә. Алар калын тышчалы күзәнәкләр төркеменнән тора.

5. Үткәргеч тукымалар – көпшәкчекләр яки каналлар рәвешендәге тре яки үлгән күзәнәкләрдән барлыкка килә. Алар суда эрегән туклыклы матдәләрне үткәрәләр.

6. Төп тукымалар – япма, механик һәм үткәргеч тукымалар арасындагы пространствоны алып тора. Күзәнәкләре нинди функция башкаруларына бәйле рәвештә, бу тукымаларның берничә төрен аерып йөртәләр. Аларның төп функциясе – төрле матдәләрне синтезлау һәм запаска туплау.

7. Ясалгы тукыма – күзәнәкләре вак, юка тышчалы һәм чагыштырмача эре төшле була. Алар яңа күзәнәкләр барлыкка китереп бүленәләр, бу яңа күзәнәкләрдән башка тукымалар формалаша.

8. Бактерияләр – чагыштырмача гади төзелешле бер күзәнәкле микроскопик организмнар.

формалары: коклар-шарсыман

бциллалар - таякчыксыман

спириллалар – спиральсыман

вибрионнар – өтер кебек бөгелгән

9. Сапротрофлар – органик матдәләрне үлгән организмнардан яки тере организмнарның бүлендекләреннән алучылар.

10. Паразитлар – тере организмнарның органик матдәләре белән тукланучылар.

11. Бактерияләрнең споралары – уңайсыз шартларда яшәргә җайлашуы.